ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29 октябрь 2025 ел

№ 8859

«2026-2028 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасы турында

Яр Чаллы шәһәре халкы сәламәтлеген саклау һәм ныгыту өчен шартлар тудыру һәм җәмгыятьнең төрле катлауларын физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүгә җәлеп итү максатында, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Бердәм халык хакимияте системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 41 статьясы, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. «2026-2028 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасын кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә 2026-2028 елларга Яр Чаллы шәһәрендә физик культура һәм спортны үстерү муниципаль программасын тормышка ашыру буенча чараларны финанслауны Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетында «Массакүләм спорт» 1102 һәм «Югары казанышлар спорты» 1103 бүлекләре (бүлекчәләре) буенча каралган акчалар хисабына 2 774 015,02 мең сум күләмендә тәэмин итәргә: 2026 ел – 880 326,92 мең сум, 2027 ел – 946 844,05 мең сум, 2028 ел – 946 844,05 мең сум.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары В.Х. Харисовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2025 елның 29 октябрендәге
8859 номерлы карарына
кушымта

1 бүлек. «2026-2028 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасының паспорты

<table>
<tr><td>Программаның исеме</td><td colspan="5">«2026-2028 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасы (алга таба – Программа)</td></tr>
<tr><td>Программаны эшләү өчен нигез (хокукый актның исеме, номеры һәм датасы)</td><td colspan="5">«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» 2007 елның 4 декабрендәге 329-ФЗ номерлы Федераль закон, «Бердәм халык хакимияте системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 5 мартындагы 159 номерлы Карары белән расланган «2019-2026 елларга Татарстан Республикасында физик культура һәм спортны үстерү» дәүләт программасы</td></tr>
<tr><td>Программаны төп эшләүчеләр</td><td colspan="5">Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе</td></tr>
<tr><td>Программаны үтәүчеләр</td><td colspan="5">Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе, муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре</td></tr>
<tr><td>Программаның максаты</td><td colspan="5">Халыкның төрле катлауларын физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүгә җәлеп итү</td></tr>
<tr><td>Программаның бурычлары</td><td colspan="5">1. Халыкны физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүгә, сәламәт яшәү рәвеше алып баруга мотивацияләүне арттыру.<br>2. Югары казанышлар спортын үстерү. Спорт резервын әзерләүнең нәтиҗәле системасын булдыру</td></tr>
<tr><td>Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары</td><td colspan="5">1 этап – 2026 ел<br>2 этап – 2027 ел<br>3 этап – 2028 ел</td></tr>
<tr><td rowspan="6">Еллар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләме һәм чыганаклары</td><td rowspan="2">Финанслау чыганаклары (мең сум)</td><td colspan="4">Программаны тормышка ашыру еллары</td></tr>
<tr><td>2026 ел</td><td>2027 ел</td><td>2028 ел</td><td>Тормышка ашыру чорында барлыгы</td></tr>
<tr><td>Муниципаль бюджет</td><td>880 326,92</td><td>946 844,05</td><td>946 844,05</td><td>2 774 015,02</td></tr>
<tr><td>Федераль бюджет</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Республика бюджеты</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>880 326,92</td><td>946 844,05</td><td>946 844,05</td><td>2 774 015,02</td></tr>
</table>

| | |
|---|---|
| Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре | Программаны тормышка ашыру нәтиҗәсендә 2028 елга түбәндәгеләр күздә тотыла:<br>1) физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүче гражданнар өлешен гомуми халык санының 71 % ына кадәр арттыру;<br>2) физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүче сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле затлар һәм инвалидлар өлешен әлеге категориядәге халыкның гомуми санының 25 % ына кадәр арттыру;<br>3) ГТО БФСК нормативларын үтәгән халык өлешен ГТО БФСК үтәүдә катнашкан халыкның гомуми санының 40 % ына кадәр арттыру;<br>4) спортчыларның спорт төрләре буенча республика, бөтенроссия һәм халыкара ярышларда алга таба да катнашуына ярдәм итү |
| Программаны тормышка ашыруны контрольдә тотуны оештыру системасы | Программаны тормышка ашыруны контрольдә тотуны Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе гамәлгә ашыра |

## 2 бүлек. Программаны раслау кирәклеге турында аңлатма язуы

Яр Чаллы шәһәренең социаль-икътисадый бурычларын хәл итү контекстында физик культура һәм спортны үстерү халык сәламәтлеген ныгыту, эшкә сәләтен, гомер озынлыгын арттыру һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру өчен мөһим ресурс буларак карала. Халык сәламәтлеген билгели торган мөһим фактор булып Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче һәр кешенең бөтен гомере дәвамында оптималь физик активлыкны саклап калу тора. Күрсәтелгән бурычлар муниципаль Программаны тормышка ашырганда хәл ителергә мөмкин.

Моннан тыш, Яр Чаллы шәһәренең халыкны физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә җәлеп итү, халыкның сәламәтлек торышы, шәһәр спортчыларының шәһәр, республика, бөтенроссия, халыкара дәрәҗәдәге ярышларда ирешкән уңышлар шәһәрнең спорт имиджын алга этәрүдә бәхәссез дәлил булып тора.

Максатчан программа методының төп өстенлекләре:

1) проблеманы хәл итүгә комплекслы якын килү;

2) вәкаләтләрне һәм җаваплылыкны бүлү;

3) программаны тормышка ашыру йомгакларын нәтиҗәле планлаштыру һәм мониторинглау.

Барлык программа чараларын уңышлы тормышка ашыру түбәндәгеләргә мөмкинлек бирәчәк:

- Яр Чаллы шәһәренең физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүче, шул исәптән сәламәтлекләре буенча мөмкинлекләре чикле кешеләре санын арттырырга;
- спорт резервы һәм югары классы спортчылар әзерләргә;
- физик культура һәм спорт тармагы хезмәткәрләренең һөнәри компетентлыгын арттырырга;
- шәһәрнең спорт имиджын күтәрергә;
- физик культураны һәм сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау системасын оештырырга.

Сәламәт, психологик яктан тотрыклы, акыл һәм физик эшчәнлеге югары дәрәҗәдәге кеше актив яши, төрле кыенлыкларны уңышлы җиңә һәм җәмгыятькә файдалы була ала.

Шулай итеп, физик культура һәм спортны үстерү – нәтиҗәле социаль сәясәтнең мөһим юнәлешләреннән берсе.

## 3 бүлек. Әлеге Программаның төп максатлары, бурычлары. Аны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары

Программаның максаты булып җәмгыятьнең төрле катлауларын физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүгә җәлеп итү.

Әлеге максатка ирешү өчен түбәндәге төп бурычларны хәл итәргә кирәк:

1. Халыкны физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүгә, сәламәт яшәү рәвеше алып баруга мотивацияләүне арттыру.

2. Югары казанышлар спортын үстерү. Спорт резервын әзерләүнең нәтиҗәле системасын булдыру;

Әлеге бурычларны хәл итү «Физкультура-спорт чаралары» һәм «Спортны үстерү буенча чаралар» юнәлешләре буенча Программага керә торган чаралар кысаларында гамәлгә ашырылачак.

Программаны тормышка ашыру 3 елга (2026-2028 еллар) исәпләнгән һәм 3 этапта гамәлгә ашырылачак.

Беренче этап (2026 ел) түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1) физкультура-спорт оешмаларын ирекле сертификацияләүне уздыру;

2) физик культура һәм спорт белгечләренең квалификациясен күтәрүне тәэмин итү;

3) шәһәр Хакиме стипендияләрен һәм югары квалификацияле спортчыларны бер тапкыр бирелә торган бүләкләү юлы белән физик культура һәм спорт өлкәсендә талантлы шөгыльләнүчеләргә ярдәм күрсәтү;

4) балалар, яшүсмерләр, студентлар, гаилә, ветераннар спортын, яшәү урыны буенча физик культура һәм спортны үстерү чараларын гамәлгә ашыру;

5) сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле затлар өчен чаралар үткәрү;

6) массакүләм мәгълүмат чаралары һәм интернет-ресурслар аша физик культура һәм спортны пропагандалауны көчәйтү;

7) югары квалификацияле спортчыларның тренировка процессын материаль-техник, методик һәм программа белән тәэмин итү;

8) дәүләт-шәхси партнерлыкны җәлеп итеп, спорт инфраструктурасын үстерү;

9) шәһәр территориясендә физик культура үсеше өчен шартларны тәэмин итүгә бәйле чараларны тормышка ашыру.

Беренче этап дәвамында түбәндәгеләр планлаштырыла:

1) Яр Чаллы шәһәренең физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүче гражданнарының өлешен 69 процентка кадәр арттыру;

2) физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүче сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле затлар һәм инвалидлар өлешен әлеге категориядәге халыкның гомуми санында 24 процентка кадәр арттыру;

3) ГТО БФСК нормативларын үтәгән халык өлешен ГТО БФСК үтәүдә катнашкан халыкның гомуми санында 39 процентка кадәр арттыру.

Икенче этап (2027 ел) түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1) физкультура-спорт оешмаларын ирекле сертификацияләүне уздыру;

2) физик культура һәм спорт белгечләренең квалификациясен күтәрүне тәэмин итү;

3) шәһәр Хакиме стипендияләрен һәм югары квалификацияле спортчыларны бер тапкыр бирелә торган бүләкләү юлы белән физик культура һәм спорт өлкәсендә талантлы шөгыльләнүчеләргә алга таба да ярдәм күрсәтү;

4) физик культура һәм спортны пропагандалау чараларын гамәлгә ашыру;

5) яшәү урыны буенча балалар, яшүсмерләр, студентлар, гаилә, ветераннар спортын, физик культураны үстерү чараларын гамәлгә ашыру;

6) сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле затлар өчен чаралар үткәрү;

7) югары квалификацияле спортчыларның тренировка процессын материаль-техник, методик һәм программа белән тәэмин итү;

8) дәүләт-шәхси партнерлыкны җәлеп итеп, спорт инфраструктурасын үстерү;

9) шәһәр территориясендә физик культура үсеше өчен шартларны тәэмин итүгә бәйле чараларны тормышка ашыру.

Икенче этап дәвамында түбәндәгеләр планлаштырыла:

- Яр Чаллы шәһәренең физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүче гражданнарының өлешен 70 процентка кадәр арттыру;

- физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүче сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле затлар һәм инвалидлар өлешен әлеге категориядәге халыкның гомуми санында 24,5 процентка кадәр арттыру;

- ГТО БФСК нормативларын үтәгән халык өлешен ГТО БФСК үтәүдә катнашкан халыкның гомуми санында 39,5 процентка кадәр арттыру.

Өченче этап (2028 ел) түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1) физкультура-спорт оешмаларын ирекле сертификацияләүне уздыру;

2) физик культура һәм спорт белгечләренең квалификациясен күтәрү буенча алга таба эшләү;

3) шәһәр Хакиме стипендияләрен бирү һәм югары квалификацияле спортчыларны бер тапкыр бирелә торган бүләкләү юлы белән физик культура һәм спорт өлкәсендә талантлы шөгыльләнүчеләргә алга таба да ярдәм күрсәтү;

4) физик культура һәм спортны пропагандалау чараларын гамәлгә ашыру;

5) яшәү урыны буенча балалар, яшүсмерләр, студентлар, гаилә, ветераннар спортын, физик культураны үстерү чараларын гамәлгә ашыру;

6) сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле затлар өчен чаралар үткәрү;

7) югары квалификацияле спортчыларның тренировка процессын материаль-техник, методик һәм программа белән тәэмин итү;

8) дәүләт-шәхси партнерлыкны җәлеп итеп, спорт инфраструктурасын үстерү;

9) шәһәр территориясендә физик культура үсеше өчен шартларны тәэмин итүгә бәйле чараларны тормышка ашыру.

Өченче этап дәвамында планлаштырыла:

- Яр Чаллы шәһәренең физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүче гражданнарының өлешен 71 процентка кадәр арттыру;

- физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүче сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле затлар һәм инвалидлар өлешен әлеге категориядәге халыкның гомуми санында 25 процентка кадәр арттыру;

- ГТО БФСК нормативларын үтәгән халык өлешен ГТО БФСК үтәүдә катнашкан халыкның гомуми санында 40 процентка кадәр арттыру;

- спорт төрләре буенча бөтенроссия һәм халыкара ярышларда чыгыш ясаучы спортчылар өлешен саклап калу.

## 4 бүлек. Программа чараларының исемлеге

Программа чараларының исемлеге әлеге Программаның 8 бүлегендә күрсәтелгән.

Халыкның физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүгә җәлеп ителү дәрәҗәсен арттыру өлешендә халыкның төрле категорияләре арасында спорт төрләре буенча чемпионатлар, беренчелекләр, кубоклар, массакүләм ярышлар, шул исәптән шәһәр Хакиме Кубогына, халык-милли уеннары һәм ярышлар уздыру күздә тотыла.

Югары казанышлар спортын үстерү чаралары. Спорт резервын әзерләүнең нәтиҗәле системасын булдыру түбәндәгеләрне күздә тота:

1) физик культура һәм спорт өлкәсендә талантлы укучыларга шәһәр Хакиме стипендияләрен түләү юлы белән ярдәм итүне тәэмин итү;

2) муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең физик культура һәм спортта югары һөнәри осталыклары өчен шәһәр Хакиме премиясен бирү;

3) Яр Чаллы шәһәренең әйдәүче спортчыларына халыкара һәм бөтенроссия ярышларында спорт казанышлары өчен бер мәртәбә бирелә торган түләүләр һәм айлык

стипендияләр түләүне тәэмин итү;

4) спорт әзерлеге программасын түбәндәге спорт төрләре буенча гамәлгә ашыру: баскетбол, волейбол, җиңел атлетика, спорт ориентлашуы, дзюдо, каратэ киокусинкай, кикбоксинг, йөзү, синхрон йөзү, нәфис гимнастика, велоспорт, спорт гимнастикасы, теннис, тимераякта шуу спорты, футбол, велоспорт (шоссе), билбау көрәше, грек-рим көрәше, армреслинг, көрәш, тхэквондо, төрле стильле каратэ, батутта сикерү, акробатик юл, спорт акробатикасы, бокс, авыр атлетика, чаңгы ярышлары, бию спорты, ат спорты, спорт туризмы, өстәл теннисы, бадминтон, җилкәнле спорт, фехтование, пауэрлифтинг, хоккей, тимераякта фигуралы шуу, шахмат.

## 5 бүлек. Программаның нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары

Программаны тормышка ашыруның арадаш һәм ахыргы нәтиҗәләрен бәяләү өчен нәтиҗәлелекне бәяләүнең түбәндәге индикаторлары файдаланыла:

| № т/б | Индикаторның исеме | Исәпләү методикасы | Чыганак |
|---|---|---|---|
| 1 | Физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүче халык өлеше, 3 яшьтән һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге халыкның гомуми санында, % | Дз = Чз / Чн х 100, монда:<br>Дз – физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүче шәһәр халкының чагыштырма авырлыгы,<br>Чз – физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүчеләр саны;<br>Чн – статистика мәгълүматлары буенча халык саны | «Физик культура һәм спорт турында мәгълүматлар» №1-ФК формасы буенча статистик күзәтү мәгълүматлары |
| 2 | Физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүче сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле затлар һәм инвалидлар өлеше, халыкның әлеге категориясендәге гомуми санда, % | Ди = Чзи /Чни х 100, монда:<br>Ди – физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүче физик мөмкинлекләре чикле затлар һәм инвалидлар өлеше;<br>Чзи – физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүче физик мөмкинлекләре чикле затлар һәм инвалидлар саны;<br>Чни – мөмкинлекләре чикле халык һәм инвалидлар саны | «Адаптив физик культура һәм спорт турында мәгълүматлар» №3-АФК формасы буенча статистик күзәтү мәгълүматлары |
| 3 | «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексы нормативларын үтәгән халык өлеше, ГТО нормативларын үтәүдә катнашкан халыкның гомуми санында, % | Дв=Чв / Чп х 100, монда:<br>Дв – ГТО нормативларын үтәгән халык өлеше;<br>Чв – ГТО нормативларын үтәгән затлар саны;<br>Чп – ГТО үтәүдә катнашкан халык саны | «Хезмәткә һәм оборонага әзер» Бөтенроссия физкультура-спорт комплексын тормышка ашыру турында мәгълүматлар» 2-ГТО формасы буенча статистик күзәтү мәгълүматлары |
| 4 | Халыкның төрле категорияләре арасында | N – сан | Башкарма комитетның спорт төрләре буенча чемпионатлар, |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | спорт төрләре буенча чемпионатлар, беренчелекләр, кубоклар, массакүләм ярышлар, шул исәптән Хаким Кубогы, халык-милли уеннары һәм ярышлар, бердәмлек | | беренчелекләр, кубоклар, массакүләм ярышлар, шул исәптән Хаким Кубогы, халык-милли уеннары һәм ярышлар оештыру һәм үткәрү турында карарлары |
| 5 | Хаким стипендиясен алган балалар һәм яшүсмерләр саны, кеше | N – сан | «Спорт өлкәсендә Яр Чаллы шәһәре Хакименең исемле стипендияләрен билгеләү турында» шәһәр Хакиме Карары |
| 6 | Шәһәр Хакиме премиясен алган физик культура һәм спорт муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең саны, кеше | N – сан | «Физик культура һәм спорт муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренә шәһәр Хакиме стипендиясен билгеләү турында» шәһәр Хакиме Карары |
| 7 | Россия, Европа, Дөнья чемпионатлары һәм беренчелекләре, Олимпия уеннары, Бөтендөнья Универсиадасы, Россия яшьләре һәм укучылары Спартакиадасы бүләкләрен алучыларның саны, кеше | N – сан | Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәренең әйдәүче спортчыларына халыкара һәм бөтенроссия ярышларында ирешкән уңышлары өчен айлык стипендияләр түләү турында» карары;<br>Башкарма комитетның «Халыкара һәм бөтенроссия ярышларында ирешкән уңышлары өчен спортчыларга бер тапкыр бирелә торган түләү турында» карары |
| 8 | Югары спорт осталыгы этабында спорт әзерлеге программаларын тормышка ашыру нәтиҗәләре буенча спортның тиешле төре буенча спорт әзерлегенең федераль стандарты таләпләрен үтәгән спорт әзерлеге узучы затлар өлеше, % | A / B x 100, монда:<br>A - югары спорт осталыгы этабында спорт әзерлеге программаларын тормышка ашыру нәтиҗәләре буенча спорт әзерлегенең тиешле спорт төре буенча федераль стандарт таләпләрен үтәгән спорт әзерлеге узган затлар саны,<br>B - югары спорт осталыгы этабында спорт әзерлеге программаларын тормышка ашыру нәтиҗәләре буенча тиешле спорт төре буенча спорт әзерлеге узган затларның гомуми саны | Физик культура һәм спорт учреждениеләре тарафыннан муниципаль йөкләмәләр үтәлеше турында хисап |
| | Спорт осталыгын камилләштерү этабында спорт әзерлеген узган һәм югары спорт осталыгы этабына кабул ителгән затлар өлеше, % | A / B x 100, монда:<br>A - спорт осталыгын камилләштерү этабында спорт әзерлеген узган һәм югары спорт осталыгы этабына кабул ителгән затлар саны,<br>B - спорт осталыгын камилләштерү этабында | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | спорт әзерлеге узган затларның гомуми саны | |
| | Тренировка этабында спорт әзерлеге узган (спорт белгечлеге этабы) һәм спорт осталыгын камилләштерүнең бөтен этабына кабул ителгән затлар өлеше, % | A / B x 100, монда:<br>A - тренировка этабында спорт әзерлеген узган (спорт белгечлеге этабы) һәм спорт осталыгын камилләштерүнең бөтен этабына кабул ителгән затлар саны,<br>B - тренировка этабында спорт әзерлеге узган затларның гомуми саны (спорт белгечлеге этабы) | |
| | Башлангыч әзерлекнең бөтен этабында спорт әзерлеге узган һәм тренировка этабына (спорт белгечлегенә) кабул ителгән затлар өлеше, % | A / B x 100, монда:<br>A - башлангыч әзерлекнең бөтен этабында спорт әзерлеге узган һәм тренировка этабына (спорт белгечлегенә) кабул ителгән затлар саны<br>B - башлангыч әзерлекнең бөтен этабында спорт әзерлеге узган затларның гомуми саны | |
| | Контингент сакланышы (спорт белгечлегенең иң соңгы тренировкалар этабында, спорт осталыгын һәм югары спорт осталыгын камилләштерү этапларында федераль стандарт таләпләрен тулы күләмдә үтгән һәм чыгарылыш статусына ия затлардан тыш), % | C=Укуг / Унуг x 100, монда:<br>C - контингент сакланышы;<br>Укуг - тренировка елы ахырына шөгыльләнүчеләр саны;<br>Унуг - тренировка елы башына шөгыльләнүчеләр саны | |

6 бүлек. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

Программа чараларын тормышка ашыру өчен 2 774 015,02 мең сум күләмендә муниципаль бюджет акчаларыннан файдалану күздә тотыла: 2026 ел – 880 326,92 мең сум, 2027 ел – 946 844,05 мең сум, 2028 ел – 946 844,05 мең сум.

7 бүлек. Программаны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү

Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе, муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре үз компетенциясе чикләрендә программа чараларын тормышка ашыру өчен шартлар тудыралар.

Программаны тормышка ашырудан социаль-икътисадый нәтиҗәлелек түбәндәгеләр хисабына ирешелә:

1) Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүче кешеләр өлешен арттыру;

2) республика, бөтенроссия һәм халыкара ярышларда шәһәр спортчылары ирешкән нәтиҗәләрне үстерү;

3) физик культура һәм спорт өлкәсе хезмәткәрләренең һөнәри компетентлыгы дәрәҗәсен күтәрү;

4) балаларны һәм яшьләрне спорт белән даими шөгыльләнүгә җәлеп итү;

5) мөмкинлекләре чикле кешеләрне физик тернәкләндерү һәм социаль адаптацияләү өчен мөмкинлекләрне киңәйтү;

6) ялның актив формаларында һәм физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүдә шәһәр халкы ихтыяҗларын канәгатьләндерү.

8 бүлек. «2026-2028 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә физик культура һәм спортны үстерү» программасының максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм программа чаралары буенча финанслау

| № т/б | Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның зурлыгы | | | | Финанслау чыганакларын күрсәтеп, мең сум | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| Программаның максаты: Җәмгыятьнең төрле катлауларын физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүгә җәлеп итү | | | | | | | | | | | |
| Бурычның исеме: Халыкны физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүгә җәлеп итү дәрәҗәсен арттыру | | | | | | | | | | | |
| 1. | Халыкның төрле яшь төркемнәре арасында бөтенроссия, республика, муниципаль физкультура-сәламәтләндерү, комплекслы, спорт чаралары, фестивальләр үткәрү | Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе | ел саен | Физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүче халык өлеше, халыкның гомуми санында, % | 68 | 69 | 70 | 71 | | | |
| 2. | Сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле затлар һәм инвалидлар арасында муниципаль физкультура-сәламәтләндерү, комплекслы чаралар, фестивальләр, спорт бәйрәмнәре үткәрү | Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе | ел саен | Физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүче сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле затлар һәм инвалидлар өлеше, халыкның әлеге категориясендәге гомуми санында, % | 23,5 | 24 | 24,5 | 25 | | | |
| 3. | Халыкның төрле яшь | Башкарма | ел саен | «Хезмәткә һәм | 38,5 | 39 | 39,5 | 40 | | | |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | төркемнәре арасында «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексын популярлаштыруга юнәлдерелгән чаралар оештыру һәм үткәрү | комитетның физик культура һәм спорт идарәсе | | оборонага әзер» (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексы нормативларын үтәгән халык өлеше, ГТО нормативларын үтәүдә катнашкан халыкның гомуми санында, % | | | | | | | |
| 4. | Халыкның төрле яшь категорияләре арасында спорт төрләре буенча чемпионатлар, беренчелекләр, кубоклар, шул исәптән шәһәр Хакиме Кубогы, халык-милли уеннары һәм ярышлар үткәрү | Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе | ел саен | Спорт төрләре буенча чемпионатлар, беренчелекләр, кубоклар, массакүләм ярышлар саны, берәмлек | 68 | 68 | 68 | 68 | Муниципаль бюджет | | |
| | | | | | | | | | 2 801,60 | 2 801,60 | 2 801,60 |
| Бурычның исеме: Югары казанышлар спортын үстерү. Спорт резервын әзерләүнең нәтиҗәле системасын булдыру | | | | | | | | | | | |
| 5. | Шәһәр Хакиме стипендияләре түләү юлы белән физик культура һәм спорт өлкәсендә талантлы укучыларга ярдәм күрсәтү | Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе | ел саен | Хаким стипендиясен алучы балалар һәм яшүсмерләр саны, кеше | 10 | 10 | 10 | 10 | Муниципаль бюджет | | |
| | | | | | | | | | 120,0 | 120,0 | 120,0 |
| 6. | Югары һөнәри осталыклары өчен муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре хезмәткәрләренә шәһәр Хакиме премиясен бирү | Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе | ел саен | Хаким премиясен алучы муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре хезмәткәрләре саны, кеше | 15 | 15 | 15 | 15 | Муниципаль бюджет | | |
| | | | | | | | | | 390,6 | 390,6 | 390,6 |
| 7. | Халыкара һәм бөтеноссия | Башкарма | ел саен | Россия, Европа, дөнья чемпионатларында, | 40 | 20 | 22 | 25 | Муниципаль бюджет | | |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | ярышларында югары спорт казанышлары өчен Яр Чаллы шәһәренең әйдәүче спортчыларына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү һәм айлык стипендия түләү | комитетның физик культура һәм спорт идарәсе | | Олимпия уеннарында, Бөтендөнья Универсиадасында, Россия яшьләр һәм укучылар Спартакиадасында бүләкләр алган җиңүчеләр һәм призерлар саны, кеше | | | | | 9 400,00 | 9 400,00 | 9 400,00 |
| 8 | Түбәндәге спорт төрләре буенча спорт әзерлеге программасын гамәлгә ашыру: баскетбол, волейбол, җиңел атлетика, спорт ориентлашуы, дзюдо, каратэ киокусинкай, кикбоксинг, йөзү, синхрон йөзү, нәфис гимнастика, велоспорт, спорт гимнастикасы, теннис, тимераякта узышу спорты, футбол, велоспорт (шоссе), регби, билбаулы көрәш, грек-рим көрәше, армреслинг, көрәш, тхэквондо, күп стильдәге каратэ, батутта сикерү, акробатика юлы, спорт акробатикасы, бокс, авыр атлетика, чаңгы узышлары, бию спорты, ат спорты, спорт туризмы, өстәл теннисы, бадминтон, җилкәнле спорт, | 16 муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре | ел саен | Югары спорт осталыгы этабында спорт әзерлеге программаларын тормышка ашыру нәтиҗәләре буенча тиешле спорт төре буенча федераль спорт әзерлеге стандарты таләпләрен үтәгән һәм спорт әзерлеге узган затлар өлеше, % | 80 | 80 | 80 | 80 | 867 614,72 | 934 131,85 | 934 131,85 |
| | | | | Спорт осталыгын камилләштерү этабында спорт әзерлеге узган һәм югары спорт осталыгы этабына кертелгән затлар өлеше, % | 10 | 10 | 10 | 10 | | | |
| | | | | Тренировкалар этабында (спорт белгечлеге этабы) спорт әзерлеген узган һәм спорт осталыгын камилләштерүнең барлык этабына кертелгән затлар өлеше, | 20 | 20 | 20 | 20 | | | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | фехтование, пауэрлифтинг, хоккей, тимераякта фигуралы шуу, шахмат | | | % | | | | | | |
| | | | | Башлангыч әзерлекнең барлык этапларында спорт әзерлеге узган һәм тренировкалар (спорт белгечлеге) этабына кертелгән затлар өлеше, % | 70 | 70 | 70 | 70 | | |
| | | | | Контингент саклanышы (спорт белгечлегенең иң соңгы тренировкалар этабында, спорт осталыгын һәм югары спорт осталыгын камилләштерү этапларында федераль стандарт таләпләрен тулы күләмдә үтәгән һәм чыгарылыш статусына ия затлардан тыш), % | 70 | 70 | 70 | 70 | | |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы

Н.И. Галиева